**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы**

КАРАР

№ 57 7 февраль 2018 ел

**Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы рәисе**
**2017 елда җирлекнең социаль-икътисади үсешен һәм 2018 елга фаразлау турында отчеты**

Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 2017 елда җирлекнең социаль – икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фаразлар буенча хисабын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң. Яңа Аксубай авыл җирлеге советы 2017 елда авыл халкы мәнфәгатьләрендә эшләр башкарды. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 6.10.2003 ел, №131-ФЗ Россия Федерациясе законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы **карар** кабул итте:

1.Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы Рәисе М.М. Сөләйманкинның авыл җирлегенең 2017 елгы социаль – икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.

2.2018 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсешенең төп бурычы-халыкның тормыш сыйфатын үстерүне тәэмин итү.

3.Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирү.

4.Яшьләрне авылга беркетү өчен кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә тормышка ашырыла торган программалар мөмкинлекләреннән файдаланырга.

5.Халыкның тормыш дәрәҗәсен киметмәү һәм гражданнарның социаль хезмәтләрдән тигез файдалануын тәэмин итү буенча чаралар күрү.

6.Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү һәм гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм абруен ныграк яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.

7.Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү чараларын дәвам итү.

8.Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында әйтелгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә..

9.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.

10.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге
Совет Рәисе: М.М. Сөләйманкин